МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 21.03.2019 № 104-пр

г.Казань

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең тәкъдим ителгән административ регламентын расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. «Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 2017 елның 9 февралендәге № 254-р карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министрлыгының
21.03.2019 № 104-пр
карары белән расланды

# Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясының 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртипләрен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар, гаммәви сервитутлар билгеләмичә урнаштырырга (алга таба – объектларны урнаштыру) рөхсәт бирү Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, № 540 боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторы нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төренә ярашлы рәвештә җир кишәрлекләрен куллана алмау мөмкинлегенә китерми дигән шарт белән, нинди дә булса хокукта гражданнарга яки юридик затларга бирелмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә әлеге Регламент нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламент «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы № 38-ФЗ Федераль законы нигезендә гамәлгә ашырылган тышкы реклама чарасы булган төзекләндерү объектларын урнаштыру очракларына кагылмый.

1.3. Дәүләт хезмәтен алучылар – физик һәм юридик затлар.

Дәүләт хезмәтен алырга гариза бирүчеләр булып дәүләт хезмәтен алучылар яки дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә эш алып баручы вәкаләтле зат (алга таба – гариза бирүче) тора.

1.4. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.4.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр. Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43 номерлы автобуслар белән «Калинин» тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

1.4.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: 221-40-39

1.4.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.4.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук, Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба –рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясенең Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 06.04.2011 № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, №15, 2036 б кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 218-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 29, 4344 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, 2338 б.);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, № 540 боерыгы («Российская газета», № 217, 24.09.2014, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында алдан килешү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү ысулларын һәм тәртибен раслау турында һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген, шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып гариза бирү, шулай ук аларның форматларына куелган таләпләр турында” 14.01.2015, № 7 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 7) (“Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы” www.pravo.gov.ru 27.02.2015);

Татарстан Республикасының Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 елның 9 февралендәге № 74 карары (“Известия Татарстана” газетасы, 14.02.1995 ел, №28, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 ел, №563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2005, № 47-48, 0985 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, №37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, №46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында” 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2011, №39, 1928 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомоствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында” 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомоствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары

норматив актлары җыентыгы” журналы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибе һәм шартларын раслау турында” 2015 елның 5 июнендәге № 416 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – карар № 416) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2015, № 45, 1554 б, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районнардагы (шәһәр округында) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур подразделениесе (офис);

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) алар нигезләнгән документлардагы мәгълүмат белән туры килмәвенә китергән Министрлык җибәргән хата (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Мөрәҗәгатьнең киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү | РФ ҖК $39^{33}$ - $39^{36}$ ст.;<br>ТР ҖК 4 ст.;<br>ПКМ № 416;<br>Нигезләмә 3.3.4 п. |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | Нигезләмә 3.3.4 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Объектларны урнаштырырга рөхсәт<br>Объектларны урнаштырырга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар. | РФ ҖК $39^{36}$ ст.;<br>ПКМ № 416;<br>Нигезләмә 3.3.4 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать кергән көннән соң 10 эш көне эчендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган. | РФ ҖК $39^{36}$ ст.;<br>ПКМ № 416 |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив- | Объектларны урнаштырырга рөхсәт алу өчен гариза белән бергә түбәндәгеләр тапшырыла (1 нче кушымта нигезендә):<br>Урнашу урынын һәм күрше җир кишәрлекләренең урнашуын төгәл күзалларга | РФ ҖК $39^{36}$ ст.;<br>ПКМ № 416. |

| | | |
|---|---|---|
| хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, шул исәптән, электрон форматта да, аларны бирү тәртибе | мөмкинлек биргән объектларның җир кишәрлегендә урнашу схемасы (1:500 масштабында ситуация планы, адресы);<br>Физик зат яисә физик яки юридик затның вәкиле булган гариза бирүченең шәхесен таныклаган документ;<br>Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаган документ (мөрәҗәгатьне гариза бирүченең вәкиле тапшырган очракта).<br>Мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазь рәвешендә түбәндәге ысуллар аша бирелә (җибәрелә) ала:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә гариза бирүче тарафынннан эш итүче зат);<br>почта аша. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында алыналар:<br>җир кишәрлеге турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРН) (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);<br>Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә (Федераль | РФ ҖК $39^{36}$ ст.;<br>ПКМ № 416 |

| | | |
|---|---|---|
| документлар сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән);<br>гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләр бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРИП) (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән);<br>Муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының объектларны урнаштырырга рөхсәте.<br>Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үз инициативасы белән тапшыра ала, шул исәптән, техник мөмкинлекләр булган очракта электрон формада да.<br>Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документлар кабул итеп алудан баш тартуга сәбәп булып тормый.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарында, башка дәүләт органнарында, җирле | |

| | | |
|---|---|---|
| | үзидарә органнарында яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган һәм башка оешмаларда булган документларны. Искәрмә булып №210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар тора.<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. Түбәндәге очраклар искәрмә булып тора:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында беренче тапкыр документлар тапшырганнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;<br>документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьтә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган һәм алдан тапшырылган документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң, | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларның срогы чыгуы яки мәгълүматның үзгәрүе;<br>дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәте күрсәткәндә зарури булган документлар кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда хаталы яки хокукларга каршы гамәленең (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачыклануы. Бу хакта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган җитәкчесе имзасы куелган хат аша белдерелә, кыенлык тудырылуы өчен гафу үтенелә. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерүләр таләп ителми. | ПКМ № 416 |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Мөрәҗәгатькә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлмәгән.<br>2. Мөрәҗәгатьтә һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартылган, өстәп язылган һәм төзәтелгән | РФ ҖК $39^{36}$ ст.;<br>ПКМ № 416. |

| | | |
|---|---|---|
| | урыннар булуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | РФ ЖК 39[36] ст.;<br>ПКМ № 416. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президенты Указы № 601, 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын регистрацияләү срогы, шул исәптән | Запрос кергән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә | |

| | | |
|---|---|---|
| электрон формада | регистрациялəнə. | |
| 2.14. Дəүлəт хезмəте күрсəтелə торган бүлмəлəргə, мөрəҗəгать итүчелəрнең көтеп тору һəм кабул ителү урыннарына, шул исəптəн, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керə алырлык булуын тəэмин итүгə карата, хезмəт күрсəтү тəртибе турында визуаль, текст һəм мультимедиалы мəгълүматка талəплəр | Дəүлəт хезмəтлəре күрсəтелү янгынга каршы система һəм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирəкле җиһазы һəм мəгълүмати стенд куелган бүлмəлəрдə башкарыла.<br>Инвалидларга каршылыксыз керə алу, шул исəптəн каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге белəн тəэмин ителə, шул исəптəн тиешле урынга килеп җитə алу максатында объект буйлап мөстəкыйль хəрəкəт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дəүлəт хезмəте күрсəтү турында визуаль, текст форматында һəм мультимедиалы мəгълүмат гариза бирүчегə уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исəптəн, инвалидларның мөмкинлеклəре чиклəнгəн булуы да күздə тотыла. | |
| 2.15. Дəүлəт хезмəтенең һəркем өчен ачык булуы һəм сыйфаты күрсəткечлəре, шул исəптəн, гариза бирүченең дəүлəт хезмəте күрсəтелгəндə вазыйфаи затлар белəн үзара бəйлəнеше саны һəм аның вакыт буенча озынлыгы, дəүлəт хезмəтен дəүлəти һəм муниципаль хезмəтлəр күрсəтү күпфункцияле үзəгендə, | Дəүлəт хезмəтенең һəркем өчен ачык булу күрсəткечлəре түбəндəгелəрдəн гыйбарəт:<br>Министрлык биналарының җəмəгать транспортына якын булуы;<br>Министрлык бинасын һəм бүлмəлəрне инвалидларга дəүлəт хезмəте күрсəтелгəн бүлмəлəргə каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һəм җиһазлар белəн тəэмин итү;<br>кирəк кадəр санда белгечлəрнең, шулай ук, | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>дәүләт хезмәте күрсәтә торган бүлмәләрнең инвалидлар өчен үтелешле булуы;<br>инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу;<br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә ике тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый; | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br>дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яисә телефоннан) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша белешә ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацмяләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала.<br>Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора. | Федераль закон № 63-ФЗ;<br>Федераль закон № 210-ФЗ;<br>Боерык № 7. |

**3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күпфункцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында**

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

гаризаны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

Объектларны урнаштырырга рөхсәт проекты яки Объектларны урнаштырырга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проекты әзерләү.

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү.

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 3 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатен Министрлыкка бирә.

Гариза һәм нотариуста яисә төп нөсхәне биргән орган (оешма) тарафыннан расланган документлар күчермәсе почта аша да юллана ала.

Мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора.

3.3.2. Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече (алга таба – эш башкару бүлеге):

мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итә;

Бүлек белгече катнашында мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булмаган очракта мөрәҗәгатьне һәм беркетелгән документларны теркәп, карау өчен Бүлеккә юллый.

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булган очракта документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече әзерләгән, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән аңлатма белән бергә, гариза бирүчегә кайтара.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган мөрәҗәгать; гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар мөрәҗәгать һәм документлар кергән көнне башкарыла, ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән мөрәҗәгать һәм документлар искәрмә булып тора.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау.

3.4.1. Бүлек белгече эш башкару бүлегеннән мөрәҗәгатьне һәм документларны алгач, төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны урнаштыруга рөхсәт бирү гаризасы үтү бите (2нче кушымта) тутыра һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада запрослар юллый:

ЕГРЮЛдан белешмә бирү турында, Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсенә (алга таба – ТР буенча ФСХИ) ;

Шәхси эшмәкәр турында ЕГРИПтан белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИга;

объектны урнаштырырга планлаштырылган җир кишәрлеге турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба - ТР буенча Росреестр);

муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының объектларны урнаштырырга рөхсәте турында (алга таба – ОМС).

3.3.2, 3.4.1 пунктлар белән билгеләнелә торган процедуралар мөрәҗәгать һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар

3.4.2. Ведомствоара арадашлык органнары белгечләре ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән, әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән запрослар нигезендә тиешле срокларда соралган белешмәләрне (документлар) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар), яисә, соралган белешмәләрнең булмавы турында Министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.5. Объектларны урнаштырырга рөхсәт проекты яки Объектларны урнаштырырга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проекты әзерләү.

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләр (документлар) алынганнан соң түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Объектларны урнаштырырга рөхсәт бирүдән баш тартырлык нигезләр булу-булмавын тикшереп чыгу;

Объектларны урнаштырырга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар проекты (алга таба – Баш тарту турында карар) яисә объектларны урнаштырырга рөхсәт проекты (алга таба – Рөхсәт) әзерләү;

Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да, объектларны урнаштырырга рөхсәт бирүдән баш тартыла:

1) мөрәҗәгать ТР МК № 416 карарының 8,9 пунктлары белән билгеләнгән таләпләр бозып бирелгән;

2) мөрәҗәгатьтә РФ ҖК 39.36 статьясының 3 пунктына нигезләнеп, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган объектлар төрләре исемлегенә кертелмәгән объектлар төрләре күзаллануы күрсәтелгән;

3) объектлар урнаштыру өчен планлаштырылган җир кишәрлеге Татарстан Республикасы милке булып тормый;

4) планлаштырылган җир кишәрлеге гражданнарга яки юридик затларга бирелгән;

5) планлаштырылган җир кишәрлегенә объектлар урнаштыру өчен рөхсәт бирү Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, № 540 боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторы нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төренә ярашлы рәвештә җир кишәрлекләрен куллана алу мөмкинлеген бетерә.

3.5.2. Бүлек мөдире Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын карап чыга, килештерә һәм килештерү өчен Җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына җибәрә.

3.5.3. Идарә башлыгы Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.5.1 – 3.5.3 пункт белән билгеләнә торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты.

3.5.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын хокук идарәсенә юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән, хокук идарәсенә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты.

3.5.5. Хокук идарәсе белгече Баш тарту турында карар проектына яисә Рөхсәт проектына хокукый экспертиза ясый (шул исәптән, проектка коррупциягә каршы экспертиза), хокук идарәсе башлыгына килештерү өчен Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын, яисә хокук идарәсе бәяләмәсе проектын (кимчелекләр булган очракта) юллый.

3.5.6. Хокук идарәсе башлыгы Баш тарту турында карар проектына яисә Рөхсәт проектына хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый яки Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.5.4 – 3.5.6 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Баш тарту турында карар проектына яисә Рөхсәт проектына хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты.

3.5.7. Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта кимчелекләрне төзәтә һәм Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын кабаттан килештерергә дип Хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.5.8. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең төзәтелү фактын тикшерә һәм тиешле проектны килештерә.

Процедура нәтиҗәсе: Хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән, Бүлек белгеченә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты.

3.5.9. Бүлек белгече хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы, хокук идарәсе башлыгы тарафыннан килештерелгән, Министрның беренче урынбасарына юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты.

3.5.10. Министрның беренче урынбасары Баш тарту турында карар проектына яисә Рөхсәт проектына кул куя һәм регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юллый.

3.5.7 – 3.5.10 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар моннан алдагы процедуралар тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә

Процедура нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары кул куйган һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә юлланган Баш тарту турында карар яисә Рөхсәт.

3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүчегә тапшыру.

3.6.1. Эш башкару бүлеге белгече Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне регистрацияли, гариза бирүчегә Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне алырга килү өчен билгеләнгән вакыт турында хәбәр итә, яисә Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне гариза бирүче күрсәткән почта адресы буенча юллый.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: эш башкару бүлегендә регистрацияләнеп, гариза бирүчегә юлланган Баш тарту турында карар яисә Рөхсәт.

3.6.2. Гариза бирүче Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне алырга килгәндә эш башкару бүлегенең документларны тапшыру өчен җаваплы белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә) ачыклый;

гариза бирүчегә Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне тапшыра һәм исәпкә алу кенәгәсенә документларның тапшырылуы турында язып куя.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән Баш тарту турында карар яисә Рөхсәт.

3.6. Дәүләт хезмәте электрон формада, күпфункцияле үзәкләр, күпфункцияле үзәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыны аша күрсәтелми.

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә киткән техник хаталарны төзәтү.

Гариза бирүченең Рөхсәттә киткән техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

3.7.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

Рөхсәтнең төп нөсхәсе;

техник хатаның булуын дәлилләгән документлар.

3.7.2. Рөхсәттә киткән техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча гаризаны гариза бирүче яки аның законлы вәкиле шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.7.3. Эш башкару бүлеге белгече гаризаны кабул итеп ала һәм, беркетелгән документлары белән бергә, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза һәм документлар тапшырылган (кергән) көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм регистрацияләнгән, карау өчен Бүлек белгеченә юлланган гариза.

3.7.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм Рөхсәткә үзгәрешләр кертү максатыннан (техник хаталарны төзәтү) Рөхсәткә үзгәрешләр кертү

проекты әзерли һәм әлеге Регламентның 3.5.1 – 3.5.10, 3.6.1 – 3.6.2 пунктларында каралган процедураларны күрсәтелгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта пунктта билгеләнгән процедуралар техник хата табылганнан соң яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан хата җибәрелү турында мөрәҗәгать алган көннән соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган Рөхсәткә әзерләнгән үзгәрешләр.

3.7.5. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документлар (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында гариза, Рөхсәткә кертелгән үзгәрешләр (техник хаталар төзәтелү белән бергә) Бүлек белгече тарафыннан Рөхсәт нөсхәсе янына беркетелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарәләр (бүлекләр) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәвен тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

канцелярия эшләрен алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү буенча планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларны бозу очраклары алдарак ачыкланып, аларның төзәтелүен тикшерү өчен;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының үз гамәлләре белән (гамәл кылмаулары белән) аларның хокукларын һәм законды мәнфәгатьләрен бозулары турында гариза бирүчеләрнең зарланып мөрәҗәгать итү очрагында.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Идарә (бүлек) эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. **Министрлыкның, вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү**

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәт күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларыннан һәм кылган (кылмаган) гамәлләреннән зарланып Министрлыкка судка кадәрге тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат таләп иткәндә, каралмаган гамәлләр кылуны сораганда;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буенча документлар бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүдән туктатып торганда, әгәр туктатып торуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән документларны һәм мәгълүматны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы яки дөрес булмавы күрсәтелмәгән очракта әлеге документларны һәм мәгълүматны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклар искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи зат яки карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы - булса), яшәү урыны турында белешмә, мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында белешмә, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында белешмә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булса), яки аларның күчермәләре теркәлә ала.

5.6. Шикаять, аны регистрацияләгәннән соң, унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган тәртип бозуларны тиз арада бетерү максатыннан Министрлык башкарган гамәлләр хакында мәгълүмат бирелә, килеп чыккан

уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче кылырга тиеш гамәлләр билгеләп үтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылмаса, әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карар турында дәлилле ачыклык кертелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
(кемнән) ________________________________________
(Ф.И.ӘИ (булганда) - физик затларга,
________________________________________
яшәү урыны
________________________________________
(гариза бирүченең шәхесен таныклаган документ реквизитлары ___________________________
урнашкан урыны (шәхси эшмәкәрләр өчен)
ГРИП турынла белешмә __________________ (шәхси эшмәкәрләр өчен)
________________________________________
тулы атамасы, оештырылу-хокукый формасы – для юридик зат өчен)
________________________________________
ГРЮЛ турында белешмә _________________________
________________________________________
(Ф.И. .(булса) ӘИ. – гариза бирүченең вәкиле өчен
________________________________________
(вәкилнең шәхесен таныклаган документ реквизитлары)
________________________________________
Гариза бирүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон адрес________________________
Телефон: _________________________________

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны урнаштыруга рөхсәт бирү турында
ГАРИЗА

Файдаланырга рөхсәт бирүегезне сорыйм (кирәклесен билгеләргә)

☐ җир кишәрлеге, мәйданы ____________________________________________ га,
кадастр номеры ____________________________________________________,
(бөтен җир кишәрлеген файдалану планлаштырылган очракта)

☐

| |территория чикләрендә түбәндәге характердагы нокталар нигезендә (күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып барганда кулланыла торган координаталар системасына кулланып) ________________________________________________________,

_________________________________________________________________________
(җирне яки җир кишәрлеген өлешчә файдалану планлаштырылганда),

Татарстан Республикасы милке булган, җир кишәрлеген бирмичә һәм урнаштыру өчен сервитут куймыйча
__________________________________________________________________________ .
(объект төре)

_______________________________________________________________________________
(җирне яки җир кишәрелеген файдалану максаты һәм объектларны урнаштыру нигезләре)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________
(объектларны урнаштыруның күздә тотылган урыны)

__________________________________________________________________________ .
Объектларны урнаштыру срогы _________________________________________________..
Объектларны РФ законнары нигезендә урнаштырганда _______________
(таләп ителә/таләп ителми)
____________________________________________________________ зонаны урнаштыру.
(җирне файдалану шартлары булган зона атамалары)

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен кәгазь документ формасында тапшыругызны сорыйм:
а) шәхсән үземә тапшырырга;
б) кәгазь документ формасында фактик яшәү урынына җибәрергә.
(кирәклесенең астына сызарга)

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№__________________________ышанычнамә буенча вәкил

__________________________________________/_______________________/
(вәкилнең фамилия, исем, этисе исеме, имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.
_______/_____________________/гаризаны алган белгечнең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте
тарафыннан билгеләнгән объектларны
Татарстан Республикасы милкендәге
җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә
урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 2 нче кушымта

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны урнаштырырга рөхсәт бирү турындагы гаризаның Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында үтү бите

Гариза бирүче ______________________________________________
Регистрация (керү) номеры _______________________

| N п/п | Министрлыкның структур бүлекчәсе | Кабул итеп алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 9. | Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге (документларны теркәү) | | | | |

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

## Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы

Гариза бирүче

Гариза бирүче (вәкил) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге белән бергә гариза

Гариза, документлар

Эш башкару бүлеге белгече

Документларны кабул итү, гариза белән документларны регистрацияләү, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерә (Бүлек белгече катнашында)

Документларны кабул итүдән баш тарту, кире кайтарылган гариза һәм документлар

Гариза бирүче

Кабул ителгән, регистрацияләнгән, Бүлеккә юлланган документлар

Бүлек белгече

Гаризаның министрлыкта үтү битен тутыра һәм ТР буенча ФСХИга, ТР буенча Росреестрга, җирле үзидарә органына запрослар юллый

Запрослар: ТР буенча ФСХИга, ТР буенча Росреестрга, җирле үзидарә органына

Министрлык запросына ТР буенча ФСХИ, ТР буенча Росреестр, җирле үзидарә органы әзерләгән белешмәләр (документлар)

Бүлек белгече

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булырлык әлеге Регламентның 2.9. п.да күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә. Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты әзерли.

Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты

Бүлек мөдире

Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проектын карап чыга һәм килештерә

Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты

Идарә башлыгы

Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проектын килештерә

Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты


Бүлек белгече
Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын хокукый экспертизага юллый.
Хокукый экспертизага юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты
Хокук идарәсе белгече
Баш тарту турында карар проектына яисә Рөхсәт проектына хокукый экспертиза ясый (шул исәптән коррупциягә каршы экспертиза)
Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты яки хокук идарәсе бәяләмәсе
Хокук идарәсе башлыгы
Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын килештерә яки хокук идарәсе бәяләмәсенә кул куя
Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты
Хокук идарәсе бәяләмәсе
Бүлек белгече
Хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне бетерә һәм Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын килештерү өчен хокук идарәсенә җибәрә
Килештерү өчен хокук идарәсенә юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты
Хокук идарәсе башлыгы
Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын килештерә
Килештерелгән Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты
Бүлек белгече
Баш тарту турында карар проектын яисә Рөхсәт проектын кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый
Кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юлланган Баш тарту турында карар проекты яисә Рөхсәт проекты


Министрның беренче урынбасары
Баш тарту турында карар проектына яисә Рөхсәт проектына кул куя һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә юллый
Имзаланган һәм эш башкару бүлегенә юлланган Баш тарту турында карар яисә Рөхсәт
Эш башкару бүлеге белгече
Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне регистрацияли һәм Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне гариза бирүчегә юллый
Гариза бирүчегә юлланган Баш тарту турында карар яисә Рөхсәт
Эш башкару бүлеге белгече
Гариза бирүчегә Баш тарту турында карарны яисә Рөхсәтне бирә
Гариза бирүчегә тапшырылган Баш тарту турында карар яисә Рөхсәт

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Тәкъдим ителгән форма

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрына
(кемнән)_________________
____

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләргә яки җир кишәрлекләренә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

Язылган:__________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
Дөрес белешмә:___________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
Объектларны урнаштыру өчен «____»_________ 20______ел №________рөхсәт кәгазендә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм тиешле төзәтмәләр кертүегезне сорыйм:

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында мәгълүматны язмача алырга риза
______________ _________________ ( ________________)
(дата) (имза) (Ф.И.ӘИ.(соңгысы - булса)

М.П.(мөһер булса)

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

## Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә урнаштырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

### Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе мөдире<br>Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |